Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Бәтке авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 13-1**

Бәтке ав. 2016 елның 3 октябре

Референдум үткәрү инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 2 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 өлешенең 1 пункты нигезендә «җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясындагы 1 пунктының «в» пунктчасы, татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Бәтке авыл җирлеге «муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы белән, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Бәтке авыл җирлеге Советы карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Бәтке авыл җирлеге территориясендә җирле референдум үткәрү инициативасын тәкъдим итү: "2016 елда Балык Бистәсе муниципаль районының Бәтке авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 200 сум күләмендә үзара салым кертүгә, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә ризамы:

- Яншык авылы, Мәктшп урамы, Кече Укмас авылы Гагарин урамы юлларны ремонтлау;
- Су башнясын ремонтлау өчен материал сатып алу Кече Укмас авылы, Киек авылында һәм Яншык авылында;
- Бәтке авылында Семен чишмәсен ремонтлау өчен материал сатып алу;
-Бәтке авылы Ленин урамында суүткәргеч торбаларны алмаштыру.

ЭЙЕ ЮК

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Бәтке авылы,Ленин урамы,4 йорт; Яншык авылы, Җиңүнең 40 еллыгы урамы, 23 йорт; Кече Укмас авылы, Гагарин урамы, 9Б йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Бәтке авыл җирлеге Башлыгы Ф.М.Динмөхәммәтов